| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **ГЛАВА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ** |

***Постановление*** ***Карар***

**2019 елның 5 нче ноябре** **Чистай шәһәре** **№ 63**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Советының
“Татарстан Республикасы “Чистай
муниципаль районы” муниципаль
берәмлегенең 2020 елга һәм 2021-2022
елларның план чорына бюджеты
турында”гы карары проекты буенча ачык
тыңлаулар үткәрү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының “Халык алдында тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында”гы 2018 елның 18 июлендәге 35/5 номерлы карары нигезендә,

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021-2022 елларның план чорына бюджеты турында”гы карары проекты буенча, ачык тыңлаулар 2019 елның 26 ноябренә 9-30 сәгатьтә Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының конференц-залында түбәндәге адрес буенча узачак: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.

2. Фикер алышына торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 йорт, 19 нчы каб. адресы буенча, яки факс буенча 5-43-70 номерына, электрон почта адресына – chistay@tatar.ru халык тыңлауларын үткәрү көненә кадәр җибәрелә. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр эш көннәрендә 8-00 дән 17-00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12-00 дән 13-00 сәгатькә кадәр) кабул ителә.

3. Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021-2022 елларның план чорына бюджеты

турында”гы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының карары проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба оештыру комитеты) тарафыннан түбәндәге составта карала:

К.В.Иванов - Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары;

Н.А.Карманова – Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе;

Р.Г.Хаматов - Данауровка авыл җирлегеннән депутат, Чистай муниципаль районы Советының Бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Г.Н.Осипов - Түбән Кондрата авыл җирлегеннән депутат, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

И.Ш.Садриева - Чистай муниципаль районы Советы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге башлыгы;

Л.Н.Абзалова - Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы;

В.Н.Белова-Реутина - Чистай муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе.

4. Боеру:

- оештыру комитетына халык алдында тыңлаулар үткәрүне, күрсәтелгән карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

- Чистай муниципаль районы финанс-бюджет палатасына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясенә халык алдында тыңлауларда әйтелгән һәм аның турында фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы утырышына проект кертергә.

5. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021-2022 елларның планлы чорына бюджеты турында”гы Карары проектын билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары К. В. Ивановка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Башлыгы Д.А. Иванов